**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«31» 07 2024 ел Яр Чаллы ш. №71

Иштирәк авыл җирлегендә 16:39:060801:50 кадастр номерлы җир кишәрлеген яңадан бүлү максатыннан ызанлау проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, район Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә, Тукай муниципаль районының җирдән файдалану һәм авыл җирлекләре төзелешен алып бару кагыйдәләре проектларын әзерләү буенча ведомствоара комиссиясенең 2023 елның 15 декабрендәге карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ**

1. Иштирәк авыл җирлегендә 16:39:060801:50 кадастр номерлы җир кишәрлеген яңадан бүлү максатыннан ызанлау проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга (tukay.tatarstan.ru).

3. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты Юл» («Светлый Путь») газетасында бастырырга.

4. Билгеләргә:

4.1. үткәрү вакытын: **2024 елның 16 августында 14:00 сәгатьтә,** үткәрү урынын: Иштирәк авылы, Үзәк ур., 116А, авыл мәдәният йорты;

4.2. материаллар белән танышу вакытын: дүшәмбе – җомга 9:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр (төшке аш тәнәфесе 12:00 сәгатьтән 13:00 сәгатькә кадәр);

4.3. тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрелә торган адресны: Яр Чаллы ш., М.Җәлил пр., 46, 203 каб.;

4.4. тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирү вакытын: 2024 елның 2 августыннан 2024 елның 16 августына кадәр.

5. Материаллар экспозициясе Иштирәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында 2024 елның 9 августыннан 2024 елның 16 августына кадәр оештырылачак.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2024 елның 31.07 81 номерлы карарына кушымта

# ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТАНАШУ ТӘРТИБЕ

Әлеге тәртип фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына район халкы тарафыннан язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Проект районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш (tukay.tatarstan.ru).

3. Проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2024 елның 2 августыннан 2024 елның 16 августына кадәр кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Яр Чаллы ш., М. Җәлил пр., 46, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 каб.

4. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук проект буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.

5. Халык тыңлаулары секретаре проект буенча фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.

6. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә.

7. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә: чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә; проект буенча фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр; фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.

8. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла.

9. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә: халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме; халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны; халык тыңлауларында катнашкан авыл җирлеге гражданнарының саны; халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

10. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм мәҗбүри рәвештә «Якты Юл» («Светлый Путь») газетасында бастырылырга һәм районның рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.